# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы
Кыр Шонталы авыл җирлеге Кече Кызыл Яр авыл торак пунктында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**2022 елның 11 октябреннән** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның 11 октябрендә узган гражданнар җыенының нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде, түбәндәге сорау буенча «Сез 2023 елда Алексеевск муниципаль районының « Кыр Шонталы авыл җирлеге»муниципаль берәмлеге территориясендәге Кече Кызыл Яр авыл торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме, 1 төркем инвалидлардан,көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына сроклы хезмәткә алынучы гражданнардан тыш, һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә сез ризамы:

- Торак пунктта урамнарны яктыртуны карап тоту (фонарьлар сатып алу һәм алыштыру).
- Техниканы карап тоту: (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча хезмәт хакы түләү).
-Авыл эчендәге юлларны төзекләндерү, карап тоту һәм ремонтлау .
- Зиратларны төзекләндерү (шартнамә буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү).

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукы булган 130 кеше кертелгән, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 83 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

«ЯКЛЫЙМ» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашкан 83 кеше тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен 0 җыенда катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1. Алексеевск муниципаль районы Кыр Шонталы авыл җирлегендәге Кече Кызыл Яр авыл торак пунктында гражданнар җыены булып узды дип таныргa, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип таныргa.

2. Сорау буенча карарны кабул ителгән дип таныргa: «Сез 2023 елда Алексеевск муниципаль районының « Кыр Шонталы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендәге Кече Кызыл Яр авыл торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум

күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме, 1 төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына срокլы хезмәткә алынучы гражданнардан тыш, һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә сез ризамы:

- Торак пунктта урамнарны яктыртуны карап тоту (фонарьларны сатып алу һәм алыштыру).
- Техниканы карап тоту: (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча хезмәт хакы түләү).
-Авыл эчендәге юлларны төзекләндерү, карап тоту һәм ремонтлау .
- Зиратларны төзекләндерү (шартнамә буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү).

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен , кабул ителгән көннән 10 көн эчендә Кыр Шонталы авыл җирлеге мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә , Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында (http://alekseevskiy.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Кыр Шонталы авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Алексеевск муниципаль районы
Кыр Шонталы авыл җирлеге башлыгы Хәммәдиев Ф.Я.